**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карары**

**2022 елның 14 декабре** **№ 82**

**"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге «414-ФЗ» Федераль законның 20 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 88, 89, 90 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1). 7 статьяның 1 өлешендәге 18 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

18) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыру;

2). 7 статьяның 1 өлешендәге 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4.1) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

3). 64 статьяның 4 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр.

4). 54 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) муниципаль һәм хосусый торак фондының торак урыннарын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану, барлык торак урыннары Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлардан;

2. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.

Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы, Совет ур., 11 й.

ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы штп, К. Маркс, 105 йорт (уку залы, китапханә бинасы)

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Дәүләтшин Раил Хәмит улына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы
поселогы"муниципаль берәмлеге Башлыгы ,
Совет рәисе Н.А. Вазыйхов